Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

2018 елның 30 ноябре № 15

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексын, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законын, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдумда кабул ителгән карарын, Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2018 елның 20 ноябрендәге 33 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын гамәлгә ашыру максатларында, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге гражданнарының узара салым акчасын җыюның тәкъдим ителегән Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Белкино авылы, Мәктәп ур., 86 йорт (административ бина) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Белкино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.Н. Меньшов

Кушымта 1
Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Белкино
авыл җирлеге башкарма
комитеты карарына үзгәрешләр
кертү хакында
2018 елның 30 ноябре № 15

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. 1 төркем инвалидлардан кала, 18 яше тулган, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар, аларның җирле референдумда катнашу, катнашмавына һәм мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2019 елның 01 апреленә кадәр үзара салым түләүне тормышка ашырырга тиеш.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (белдерү) бланкы Белкино авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында гражданнар игътибарына (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайты (www.pestreci.tatarstan.ru), һәм почта элемтәсе аша да, кулга тапшыру юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләү суммасы тулы күләмдә, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлегенең шәхси счетына керә

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча) почта күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Кушымта 2
Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Белкино
авыл җирлеге башкарма
комитеты карарына үзгәрешләр
кертү хакында
2018 елның 30 ноябре № 15

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге бюджетына үзара салым кертү буенча бер тапкыр түләү турында
БЕЛДЕРМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _____

Түләүченең Ф. И. атасының исеме
______________________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
_____________________________________________________________ нигезендә
Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: _______________ срогына кадәр, __________
суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк
Алучы Банк БИК ____________________________________
Сч. № ________________________________
Алучы Сч. № ______________________________________
ИНН ________________________________________
КПП ________________________________________
КБК _______________ ОКАТО __________________
Түләү билгеләү
______________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________________
М.П. (имза) (имза расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - -

500 (биш йөз) сум күләмендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге бюджетына үзара салым кертү буенча бер тапкыр түләү турында белдермә (уведомление) № _____

Түләүченең Ф. И. атасының исеме ________________________________________
Адрес:
______________________________________________________________________
Алды «__» _______________ 20__ ел. ______________________________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше Белкино авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*